КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.07.2019 № 67-П

г. Казань

Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында”гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы федераль закон, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, махсус җайга салына торган шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак, федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен саклауны һәм дәүләт тарафыннан саклап тотуны тәэмин итү максатларында, **боерам**:


1. Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен расларга (1 нче кушымта).
2. Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимын расларга (2нче кушымта)
3. Боерыкның үтәлүен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәис в.б. А.Р.Сәләхов

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
12.07. 2019 ел № 67-П
боерыгына
1нче кушымта

Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан федераль әһәмияткә ия
мәдәни мирас объектлары территорияләре **ЧИКЛӘРЕ**

**1.** Алабуга ш., Иске зират адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Дурова Надежда Андреевна кабере, (1783-1866 еллар)» мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картасы (схемасы)**




Мәдәни мирас объектының топографик планы

Алабуга ш., Иске зират адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Дурова Надежда Андреевна кабере, (1783-1866 еллар)» мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**

Федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты территориясенең чикләре түбәндәгечә уза:

**Көнбатыш өлеше:** Казан урамыннан торак йорт юнәлешендә тимер койма буйлап ( 1-3 борылыш нокталары);

**Төньяк өлеше**: тимер койма буйлап Троицк мәйданы юнәлешендә (3-4 борылыш нокталары);


**Көнчыгыш өлеше**: тимер койма буйлап Троицк мәйданына параллель юнәлештә Казан урамына таба ( 6-7 борылыш нокталары).

**Көньяк өлеше**: тимер койма буйлап Троицк мәйданыннан Казан урамына параллель рәвештә (7,1).

Алабуга ш., Иске зират адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Дурова Надежда Андреевна кабере, (1783-1866 еллар)» мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **борылыш нокталары таблицасы**

| № | Нокталарның МСК 16 системасында координатлары | | Нокталарның 1984 елгы (WGS-84) Бөтендөнья геодезик координатлар системасында координатлары | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | Киңлек, B | Озынлык, L |
| 1 | 472353.44 | 2300750.22 | 55°45'31.10"N | 52°02'37.37"E |
| 2 | 472357.73 | 2300750.77 | 55°45'31.24"N | 52°02'37.40"E |
| 3 | 472357.11 | 2300756.36 | 55°45'31.22"N | 52°02'37.72"E |
| 4 | 472352.76 | 2300755.85 | 55°45'31.08"N | 52°02'37.69"E |

**2.** Алабуга ш., Иске зират адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Шагыйрә Цветаева Марина Ивановна кабере (1894-1941)” мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картасы (схемасы)**




Мәдәни мирас объектының топографик планы

Алабуга ш., Иске зират адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Шагыйрә Цветаева Марина Ивановна кабере (1894-1941)” мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**

Федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты территориясенең чикләре түбәндәгечә уза:

**Көнбатыш өлеше:** капкадан таш түшәлгән юл буйлап тимер һәйкәлгә кадәр (1-2 борылыш нокталары);

**Төньяк өлеше**: тимер һәйкәлдән таш түшәлгән юл буйлап таш һәйкәлгә кадәр (2-3 борылыш нокталары);

**Көнчыгыш өлеше**: таш һәйкәл буйлап бетон коймага перпендикуляр рәвештә (3-4 борылыш нокталары).

**Көньяк өлеше**: таш һәйкәлдән бетон койма буйлап (4,1).

Алабуга ш., Иске зират адресы буенча урнашкан федераль әһәмияткә ия “Шагыйрә Цветаева Марина Ивановна кабере (1894-1941)” мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **борылыш нокталары таблицасы**

| № точки | Нокталарның МСК 16 системасында координатлары | | Нокталарның 1984 елгы (WGS-84) Бөтендөнья геодезик координатлар системасында координатлары | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | Киңлек, B | Озынлык, L |
| 1 | 473799.81 | 2302769.44 | 55°46'17.85"N | 52°04'33.21"E |
| 2 | 473805.88 | 2302768.06 | 55°46'18.04"N | 52°04'33.13"E |
| 3 | 473807.37 | 2302776.2 | 55°46'18.09"N | 52°04'33.60"E |
| 4 | 473801.27 | 2302777.46 | 55°46'17.89"N | 52°04'33.67"E |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
12.07. 2019 ел № 67-П
боерыгына
2нче кушымта

Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектлары территорияләреннән
**файдалану режимы**

Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә түбәндәгеләр **рөхсәт ителә**:

- реставрация биреме буенча эшләнгән һәм Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын саклау буенча вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан килештерелгән проект документлары нигезендә, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы (ДТМЭ) узганнан соң - мәдәни мирас объектын консервацияләү, ремонтлау һәм реставрацияләү (сак предметын тәшкил итүче үзенчәлекләрен үзгәртмичә);

-мемориаль һәм архитектура-ансамбль ягыннан кыйммәтле булган юкка чыккан архитектура һәм тарихи элементларын (култыкса рәшәткәсе, бизәү һәм б.ш.элементлар) фәнни нигездә торгызу-регенерацияләү;

-тарихи-мәдәни кыйммәте булмаган диссонанс объектларны, вакытлы корылмаларны һәм соңрак төзелгән янкормаларны юкка чыгару;

- пандуслар һәм күтәргечләр урнаштырып, мәдәни мирас объектына мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен керү мөмкинлеге тудыру;

-тарихи рельефын саклап һәм юллар, җәяүлеләр сукмаклары, күзәтү мәйданчыклары, кече архитектура формалары һәм яктырту өчен җайланмалар өслегендә традицион материаллар (агач, таш, кызыл кирпеч) кулланып, мәдәни мирас объекты территориясен төзекләндерү;

-мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше һәм табигый тирәлегендә күренүен тәэмин итү, яшеллекнең кыйммәтле булмаган төрләрен юкка чыгару (Америка өрәнгесе), агачларның һәм куакларның традицион төрләрен саклап калу, яңа яшел үсентеләр, агачларның шәһәр өчен традицион булган төрләрен утырту;

-янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм мәдәни мирас объектын динамик тәэсирләрдән саклау.

Югарыда атап үтелгән барлык эшләр Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын саклау буенча дәүләт органы тарафыннан бирелгән рөхсәт кәгазе нигезендә, дәүләт тарихи-мәдәни эскпертизасының уңай нәтиҗәсе булган

проект документларын әзерләү һәм эшләр башкару буенча йөкләмәгә, шулай ук проект документациясенә туры китерелеп башкарыла.

Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә түбәндәгеләр **тыела**:

-килештерелгән һәм тиешле рәвештә расланган махсус планга яраклы рәвештә мәдәни мирас объектын комплексны саклауга, аның тарихи-шәһәр төзелеше һәм табигый тирәлеген торгызуга бәйле булмаган төзелеш эшләре алып бару;

-инженер системаларын, коммуникацияләрен һәм җиһазларын җир өстеннән үткәрү;

-грунт суларының дәрәҗәсен үзгәртү, гидрология һ.б.ларны бозу мөмкинлегенә юл куймауны исәптә тотып эшләнгән махсус проектларсыз инженер системаларын, җиһазларын һәм территорияне төзекләндерүне башкару;

-урынның тарихи ландшафтын үзгәртү, киосклар, павильоннар, өслекләр, кече архитектура формалары урнаштыру (юкка чыкканнарны торгызу искәрмә булып тора);

-санитар кисүләрдән тыш, агачларның кыйммәтле төрләрен кисү.